| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|
| Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района | Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 01 » 07 2021 № 211

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы
Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан
муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең
административ регламентларын раслау турында»
2021 ел, 18 февраль, 62 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»27.07.2010 ел, 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 02.11.2010 ел, 880 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт йөкләмәсе (заказ) урнаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан социаль әһәмиятле дәүләт хезмәтләрен, хезмәт күрсәтүләрен электрон формада күрсәтүгә күчү чаралары планын раслау турында»13.04.2021ел, 242 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 26.11.2018 ел, 651 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтл әре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 ел, 18 февраль, 62 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 2 нче кушымтасын, карарга 1 нче кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә;

«Муниципаль милектәге җирләрдән яки җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 9 нче кушымтасын, карарга 2 нче кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә;

«Территорияләрнең кадастр планында җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 16 нче кушымтасын, карарга 16 нче кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм мөлкәт белән идарә итү буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе: С.Ю. Зайцев